**Казанский (Приволжский) федеральный университет**

**Олимпиада «Я – магистрант КФУ»**

**2022-2023 учебный год**

**Институт Филологии и межкультурной коммуникации**

**Профиль: Татарский язык и литература**

**1. Татар теленнән теоретик бирем. Түбәндә тәкъдим ителгән сорауга үз фикерегезне дәлилләп, җавап языгыз (15 балл).**

Татар телендә алмашлык сүз төркеме: алмашлыкларны өйрәнү тарихы, төркемчәләре. Алмашлыкларның килеш белән төрләнеше. Сорауга җавапны мисаллар ярдәмендә дәлилләгез.

**2. Текстны укыгыз һәм сорауларга җаваплар языгыз (15 балл).**

1) Язгы йолык туен кешеләр кояш көткән кебек көтеп алалар иде. 2) Бу көнгә һәркемнең яшерен уе-теләге була авырулар явыз ияләргә йолык биреп чирдән котылу авырлылар баладан языклылар языктан котылу турында уйлап юаналар иде 3) Йолык туеның кайчан буласы билгеле булгач, кешеләрне күңелле бер күтәренкелек биләп алды. *(Нурихан Фәттах)*

а) Тексттан искергән сүзләрне язып алыгыз; контексттан чыгып, аларның мәгънәләрен аңлатыгыз (5 б.)

ә) Икенче җөмләдә тиешле урыннарга тыныш билгеләрен куеп, җөмләне күчереп языгыз. (5 б.)

б) Өченче җөмләгә тулы синтаксик анализ ясагыз һәм схемасын төзегез (5 б.).

**3. Әдәбияттан теоретик бирем (15 балл).**

Сюжет һәм сюжет элементлары, сюжеттан тыш элементлар. Үз фикерләрегезне әсәрләрдән мисаллар аша дәлилләп языгыз.

**4. Әдәби иҗатка бәйле сорауга җавап языгыз (15 балл).**

1960-80 еллар татар әдәбиятында (проза, поэзия, драматургия) яңарыш нинди сыйфатлар белән билгеләнә? Әсәрләр нигезендә аңлатып языгыз.

**5. Иҗади бирем – эссе. Бирелгән темаларның БЕРСЕН сайлап алып, 150 сүздән артмаган эссе языгыз (40 балл).**

1. Я дөньяны үзгәртәм мин бүген,

Я, булмаса, үзем үзгәрәм. *(Разил Вәлиев)*

2. «Әдәбият ул – милләт хәтере. Халыкның гасырлар дәвамындагы холык-фигылен, яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, өмет-хыялларын, әрнү-сагышларын үзенә сеңдергән» (*Ркаил Зәйдулла*)

Әлеге шигырь юлларына һәм канатлы гыйбарәләргә бәйле үзегезнең уйлануларыгыз, уй-фикерләрегез белән уртаклашыгыз.